Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Адав-Толымбай авыл җирлегенең Адав-Толымбай авылында гражданнар җыены карары

6 декабрь 2021 ел № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Адав-Толымбай авыл җирлегенең Яңавыл авылында гражданнар җыены

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. 2022 елда Адав-Толымбай авыл җирлегенең Яңавыл авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм сайлау хокукына ия балигъ булган гражданнарның һәркайсыннан 500 сум күләмендә үзара салым җыюны кертергә.

2. Җыелган акчаны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итүгә

- Яңавыл авылында юлларны кышкы чорда кардан чистарту эшләрен башкаруга юнәлдерергә.

3. Җыен нәтиҗәләрен Адав-Толымбай авыл җирлегенең Яңавыл авылында махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Адав-Толымбай авыл җирлеге башлыгы __________ А.Ф. Әхмәтҗанов

Халык җыены секретаре __________ Г.Ш. Насертдинова